СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423181, РТ, Новошешминский район,
село Тубылгы Тау, ул.Молодежная, д.73,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423181,ТР, Яңа Чишмә районы,
Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы,
73

тел.:(8-84348)3-82-58,факс:(8-84348)3-82-44,Tub.Nsm@tatar.ru

Тубылгы Тау авыл җирлеге советы утырышы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
КАРАРЫ

2022 елның 21 нче апреле № 19-65

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганаклары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) рәсми чыганаклары итеп билгеләргә:

- районда таратыла торган вакытлы басма «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасы: www.novoshishminsk.ru;
- Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайты Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/;
- «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталы: http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»: http://pravo.tatarstan.ru;
- кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге торак пункты территориясендә махсус мәгълүмат стендлары;
- Тубылгытау авыл җирлегендә яшәүчеләргә хокукый акт текстын үзәкләштерелгән тәртиптә, шул исәптән махсус басма рәвешендә тарату.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2005 елның 22 октябрендәге 1-5 нче номерлы «Тубылгытау авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый актларын халыкка җиткерү турында»гы карары үз көчен югалткан дип

танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatrstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзеклөндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф. Исмагилов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ТУБЫЛГЫТАУСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
р 06-307/14
СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгытау авыл җирлеге
Советының 2022 елның 21 нче апреле
19-65 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары текстларын урнаштыру өчен махсус мәгълүмат стендлары исемлеге

| Агитацион басма материаллар элү өчен махсус урын адресы | Элү урынының исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), стенд (бина диварындагы игъланнар тактасы, фойеда һ. б.) | Саны, шт. |
|---|---|---|
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр ур., 73 | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |